РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«20» декабрь 2021 ел г. Альметьевск № 1879

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020 елның 2 ноябрендәге 1601 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт мәгариф оешмаларында башлангыч гомуми белем бирүнең белем бирү программалары буенча һәм башлангыч гомуми белем бирү программалары буенча белем алучыларны башлангыч гомуми белем бирүне түләүсез кайнар тукландыруны оештыру һәм тәэмин итүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2021 елның 06 сентябрендәге 826 номерлы, 2021 елның 07 сентябрендәге «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 842 номерлы карарлары нигезендә һәм кайнар тукландыруны вакытында тәэмин итү максатларында

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы гомуми белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2020елның 2 ноябрендәге 1601 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 22 декабрендәге 1906 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 3,4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Бер укучыга ата-ана кертемнәре суммасын көнгә билгеләргә:

шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында укучы өчен 47 сум 25 тиен;

гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүчеләр өчен өстәмә туклануга 26 сум 00 тиен акча».

4. Билгеләргә:

шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 1-4 сыйныфларында укучылар өчен бер укучыга бушлай кайнар туклану бәясе көнгә 55 сум;

Шәһәр һәм авыл гомуми белем бирү учреждениеләренең 5-11 сыйныфларында укучылар өчен бер укучыга балансслы кайнар туклану бәясе көнгә 55 сум 55 тиен.

гомуми белем бирү учреждениеләрендә озайтылган көн төркеменә йөрүчеләр бер укучыга өстәмә туклану бәясе көнгә 26 сум 00 тиен;

лицей-интернатның бер тәрбияләнүчесенә нисбәтле кайнар туклану бәясе көнгә148 сум 00 тиен.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2022 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2021 елның 07 сентябрендәге 842 номерлы карары нигезендә, уку елы дәвамында бер укучыга исәпләнгән көнгә 8 сум 30 тиен күләмендә акчалата түләүләр бәясе. Балансслы туклану нормативына туры китереп, аерма укучыларның ата-аналары хисабына түләнә»;

1 нче кушымтаның 2 пунктын карарга түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Укучыларны ашату 55 сум 55 тиен тәшкил итә».

2. Район Башкарма комитетының Хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе — А.М. Каюмов

ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ